ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

Тел., факс: (8-85595) 5-19-69. Leninogorsk.Ikmo@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 24 мае № 1297

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 9 февралендәге 484 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында»2020 елның 20 ноябрендәге 78 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараны уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2023 елның 6 маендагы 04-41/3249 номерлы хаты нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2023 елның 09 февралендәге 484 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

8,10 пунктларда «квартал саен» сүзен «ай саен» сүзенә алмаштырырга;

12 пунктта:

4 пунктчада «депутат кабул итүен оештыру» сүзләрен «микрорайон гражданнарын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары тарафыннан кабул итүгә ярдәм итү» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктчада «квартал» сүзен «ай» сүзенә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләре бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә компенсацион түләү бирү турында гариза.

20___ ________________________________ ел өчен

(ай)

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Компенсация түләвен алучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме | |
| 2 | Компенсация түләвен алучының яшәү адресы | |
| 3 | Компенсация түләвенең шәхесен раслаучы Паспорт мәгълүматлары яисә башка документ | |
| 4 | Компенсация түләүләрен алучының банк реквизитлары | |

Әлеге белдерүдә бәян ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

Имза, имзаны расшифровкалау

Гариза бирү датасы:

Кушымталар:

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

- «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 20________ ел _________номерлы Лениногорск шәһәре Башкарма комитеты карары территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге турында хисап, карарның 2 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча хисап.

2. Әлеге карарны «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче

урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Г. . Михайлова

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72